УДК 82

***Ситдыйкова Ч.Ф. , филология фәннәре кандидаты***

***«Language+» студиясе***

***Мәкалә «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4. санлы чарасы чикләрендә башкарылды.***

# Н.ГЫЙМАТДИНОВАНЫҢ 1990-2020 ЕЛЛАР ПРОЗАСЫНДА МОДЕРНИСТИК ТЕНДЕНЦИЯЛӘР

*Аннотация: Мәкаләдә Н.Гыйматдинованың 1990-2020 еллар прозасында мифологизм чагылышы өйрәнелә. Әсәрләрдә мифологик сюжет, мифологик образ, архетипик образ, символик детальләр һ.б. бирелеше анализлана.*

*Төп төшенчәләр: проза, мифологизм, мифологик сюжет, мифологик образ, архетипик образ, алым.*

***Sitdikova Ch.F., Candidate of Philological Sciences***

***Studio «Language+»***

# MODERNICTIC TENDENCIES IN N.GIMATDINOVA' S PROSE OF 1985-2020'S

*Abstract: The article is devoted to mythologism in N.Gimatdinova's prose of 1985-2020's. Mythological plots, mythological characters, archetypal characters, symbolic details ect. are analyzed in this work.*

*Keywords: prose, mythologism, mythological plot, mythological character, archetypal character, technique.*

Н. Гыйматдинова иҗатының киң катлау укучылар аудиториясен яулап алуы 1980 еллар ахырына туры килә. Аның гадәти булмаган вакыйгалар һәм геройлар тудырган повестьлары татар әдәбиятында өр-яңа сүз булып кабул ителә, тематик һәм фикри яңалык белән бергә, каләменең иҗат осталыгы ягыннан камилләшүе турында сөйли. Н. Гыйматдинова тирән сәяси-иҗтимагый кризис, үзгәрешләр шартларында башка кешеләрдән,

җәмгыятьтән читләшкән шәхес кичерешләрен, хисләрен, кәефен ачып бирүне беренче планга чыгара: бу чор иҗатында психологизм аеруча көчле. Геройны характер буларак күрсәтүдә эчке халәт үзгәреше: күңел төшенкелеге, читләшү, битарафлык, курку, икеләнү, җаваплылык, ялгызлык, өмет өзү, авыру, үлем кебек категорияләр-төшенчәләр мөһим урын алып тора.

Бу үзгәрешләр «Сихерче» (1989) повестеннан башланып китә. Анда язучы, татар әдәбияты өчен үзенчәлекле – табигый дәвалау сәләтенә ия хатын-кыз образы тудырып, төп игътибарын табигать-кеше, Сәвилә-кешеләр каршылыкларына юнәлтә. Әсәрнең әлеге сыйфатын ассызыклап, Р. Гыйлаҗева болай дип яза: «Язучы табигать белән кешелек җәмгыяте арасындагы каршылыкны бөтен кискенлеге белән укучылар күз алдына бастыра... Авторның героинялары – табигать белән кешеләр арасында бәйләүче чылбыр, арадашчы» [2, б. 175].

Чыннан да, әлеге гадәти булмаган героиня – табигать баласы образы ярдәмендә табигатькә җавапсыз карауның һәм аның бөтенлеген җимерүнең бик зур югалтуларга китерүе күрсәтелә, бу фикерне бөтен тулылыгында җиткерү өчен мәҗүсилек фәлсәфәсенә мөрәҗәгать ителә. Беренче карашка болынга терлек кертү, басу-кырларга сипкән ашлама – гадәти хәл кебек. Язучы моңа героиня күзе белән карарга мәҗбүр итә: ашлама сиптерелгән, тапталган болында күп кенә үсемлекләр харап булган, бөҗәкләр юкка чыккан. Табигать белән гармониядә яшәү мотивы язучы әсәрләрендә урнашып кала, алга таба да төрле яклап шәрехләнә.

Сәвилә һәм тирә-юньдәгеләр арасындагы каршылык табигатькә, гомумкешелек кыйммәтләренә төрле караштa булуларыннан, яшәү мәгънәсен төрлечә аңлауларыннан килеп чыга. Сәвилә яшьтәшләре, күршеләре, авыл һәм шәһәр кешеләре белән бәхәскә керә. Аның өчен табигать белән гармоник мөнәсәбәттә тору, матурлыкны, бөҗәкләрне, «мең төрле шифага ия» булган үләннәрне саклап калу – яшәү мәгънәсе, яшәү чыганагы. Кызу хәрәкәт, актив тормыш көтүче битараф халык аны аңларга теләми. Кешеләр геройның табигать өчен борчылуын тилелек дип кабул итәләр, «сихерче», «күз буячы»

дигән исемнәр тагалар. Бу хәлнең сәбәбен дә әдибә кешеләрнең табигый асылыннан ераклашуында күрә.

Повестьларда геройлар чиктәш халәттә, сынаулар аша узу вакытында сурәтләнә. Әйтик, «Бүре каны» (1990) повестенда урманчы Аю-Кәримнең баласы бик зәгыйфь булып туа, юктан гына үлми кала, үсә төшкәч тә «әнкәсенең итәгенә тотынып йөри». Кечкенә, җебегән, мескен, куркак, кызлар кебек елак Рамазанны авыл малайлары да кыерсыта. Бу хәлгә бик борчылган ата, баланың холкын үзгәртү максаты белән, улына бүре каны эчерә.

Әмма үзен табигать-урман хуҗасы итеп тойган Кәримнең бу адымы, ахыр чиктә, тискәре нәтиҗәләргә китерә. Беренче карашка, малайны үзгәртергә, көчле, ирекле итәргә өметләнгән ата теләгенә ирешә: бала өйгә елап кайтмый, башка малайлар белән сугыша, яшьтәшләре аннан курка. Әмма тора-бара Рамазан үчлекле, явыз кешегә әверелә. Ул укуын уңышлы тәмамлый, ялагайлык, кирәкле кешеләр белән дус булу аркасында «өскә» күтәрелә, газета редакторы итеп эшкә урнаштырыла, теләге – киләчәктә министр булу. Моның өчен ул барысына да әзер. Рамазан бүре, ерткыч кебек фикер йөртә. Ул сөйгән кызын ташлый, Фаяны көчли, Акчурин үлеменә сәбәпче була. Вакыйгалар барышы язучы фикерен ачык чагылдыра: кеше – табигатьнең бер кисәге генә, аның акыл көче табигатьне җиңүгә, буйсындыруга түгел, ә дөрес файдалануга юнәлтелгән булырга тиеш. Киресенчә икән, табигать кешедән каты һәм рәхимсез үч алачак. Әсәрдә табигать үзенең табигый яшәешенә тыкшынучыларны каты җәзалый: гөнаһсыз җанварның җанын кыеп аякка бастырылган Рамазан Закировның үлеме бүредән була. Кеше ялгышын табигать үзе төзәтә.

«Тамга» (2004) повесте да охшаш идеягә буйсындырылган. Әсәрдә бу үкенү, шуның аша үгет-нәсихәт бирү төсен ала. Сау-сәламәт аучы кисәк кенә урын өстенә кала: «Баскан саен аяк астында җир калтыратган сау-сәламәт ата, «йөрәк пешә» дип, өч көн ятакта аунады һәм бер сәер гадәте белән өнне алды. Төннәрен ул саташып бүре булып улый, бу улау җәйге авылның котын

очыра иде» [1, б. 70]. Үләр алдыннан Миннехан улына бүреләргә тимәскә куша. Табигатькә зыян салган өчен үкенү мотивы аша кеше табигать белән гармониядә яшәргә тиеш дигән фикер раслана.

Язучы ирреаль күренешләр ярдәмендә гадәти булмаган яшәү модельләрен тудыра, бу вакытта мифологик образлар һәм детальләр, мәҗүси фикерләү үзенчәлеген куллана. Әсәрләрдә тормышчан сюжет сызыгы белән янәшә мифологик сюжет сызыгы урнаша. Күпвакыт чынбарлык фонында романтик геройлар үзәккә куела, алар, бер яктан, язучыга ике төрле тормыш моделе төзергә мөмкинлек бирә (әйтик, авыл һәм урман); икенче яктан, автор мөнәсәбәтен җиткерү өчен кирәк. Язучы геройларын «чистарта», идеаллаштыра, рухи дөнья кайгысы белән генә яшәүче, материаль ваклыклардан өстен, саф һәм изге җаннар дәрәҗәсенә күтәрә [3, б. 110]. Сара һәм Арыслан («Ак торна каргышы», 1993), Хаят («Пәри утарында», 1996), Камилла («Китәм, димә», 2001) шундыйлардан.

«Пәри утарында» әсәрендә 1980-1990 еллар җәмгыятендәге күп каршылыклар тасвирлана, Рөстәм һәм аның иптәшләренә бәйле рәвештә эчкечелек, әхлаксызлык, мәрхәмәтсезлек кебек тискәре сыйфат-күренешләр сатирик бәяләнә. Бүреләр төркемендәге вакыйга-хәлләрне тасвирлау мифологик сюжет сызыгын хасил итә. Кешеләр (Хаят һәм Рөстәм) һәм бүреләр (Сорыкай һәм ак бүре) язмышы янәшә үрелеп бара. Әсәр аяныч тәмамлана: кешеләр Хаятнең яшәү урынын юк итә, утар җир белән тигезләнә. Хатынның киләчәге билгесез, ул юкка чыга. Язучы тарафыннан кулланылган яшерү, әйтеп бетермәү алымы укучыны геройның язмышы хакында уйландыра, төрле фикерләргә этәрә. Фаҗигагә китерүче төп сәбәп – «төркем»нең (кешеләр төркеме – җәмгыять, бүреләр төркеме – ыру) Хаятне, ак бүрене кабул итмәве. Язучы кешеләр җәмгыятен бүреләр өере белән чагыштыра. Нигездә, икесе дә үзләренә охшамаганнарны, аерылып торганнарны, конкретрак әйткәндә, шәхесне юк итәргә сәләтле. Язучының идеалы булган Хаятнең җәмгыятькә капма-каршы куеп сурәтләнүе хәзерге

тормышның тоташ караңгылыктан, пычраклыктан, явызлыктан торуын ассызыкларга ярдәм итә.

«Ак торна каргышы» әсәрендә дә 1990 еллар авыл тормышы, чор кешеләренә хас сыйфат-билгеләр (битарафлык, комсызлык, азгынлык, әхлакый кыйммәтләрнең үзгәрүе, җәмгыятьтәге бозыклык, башкаларга иярү һ.б.) ачыла. Саф, чиста күңелле, кешеләргә яхшылык кына кылган укытучы Сара авырып, берәүгә дә кирәксез булып кала; ул урын өстендә, үлем көтеп яшәргә мәҗбүр. Мифологик сюжет сызыгы – кешеләр һәм торналар арасындагы мөнәсәбәтләр үсү тарихы. Гүзәллек һәм сафлык символы булган пар торна Сараны яшәүгә кайтара, аякка бастыра. Әсәр азагында авыл кешеләре, азгынлык мәгънәсе салып, торналарның берсен кыйнап үтерә. Бу фаҗигагә табигать көчле давыл белән җавап бирә: язучы җиргә килгән апокалипсисны күрсәтеп, ахырзаманга китерүче сәбәпләрне билгеләп, кешелекне киләчәк хакында кисәтә.

«Болан» (1995) повестенда табигать-кеше каршылыгы мәхәббәт тарихы аша ачыла. Акчәч − табигать сакчысы булса, Рыскол – аучы, ул киек-җанвар атып көн күрә. Ирнең нәселенә ул һәлак иткән җан ияләре каргышы төшкән. Әбисе Сузгынның кисәтүенә колак салмыйча, Акчәч Рысколны коткарып калырга ниятли: боланга әверелеп, көн дә аның юлына аркылы төшә. Урманда асыл болан күрү, аны ату теләге аучының сөйгәненә биргән вәгъдәсеннән дә, мәхәббәттән дә көчлерәк булып чыга. Мөнәсәбәтләр аяныч тәмамлана: сөйгән кешесенең гомерен коткару хакына Акчәч үзен корбан итә, Рыскол болан-Акчәчне атып үтерә. Шул рәвешле әсәр нигезенә салынган ике төрле караш, яшәү фәлсәфәсе бәрелеше тормышның фаҗига булуы турындагы нәтиҗәгә ишарә ясый.

Язучының осталыгы текстны башкача уку мөмкинлекләрен дә күрсәтә. Бу яктан, әсәрдәге мифологик сурәт гаҗәеп үзенчәлекле. Хуҗалар тавы − җаннарның сафлыгын саклап торучы, табигатьнең, җирнең язмышы өчен җаваплы урын. Тауда ак һәм яшел күлмәкле изгеләр яшәеш итә, алар күп очракта табигатьне кыерсытучылардан үч ала – аларны үлемгә этәрә.

Тау образына бәйле рәвештә анимизм күренеше, кешедә генә түгел, төрле предметларда, үләннәрдә, җәнлекләрдә дә җан бар дигән караш урын таба. Тау туфрагына багышлау, төрле йолалар (имәнгә, тауга, изгеләргә мөрәҗәгать итү, тауга бүз киеп менү, 40 адымга − 40 теләк теләү һ.б.), әкияти-мифологик затлар, әйтик, кайбер төрки халыкларда тотем хайван булып саналган ак елан образы бирелеше мәҗүсилек концепциясен язучының башка әсәрләре белән чагыштырганда да тулырак, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендә аңлатырга мөмкинлек бирә.

«Күке төкереге» (1995) әсәрендә төп сюжет сызыгы бөтенләй башка юнәлеш ала: ул кара һәм ак, сихер һәм дин фәлсәфәсе бәрелешенә корыла. Авылда сихерче Карачутыр һәм им-том белән дәвалаучы дини карчык Акъәни яши. Язучы сихерче-имче-белекчеләр тормышын, алар хакындагы уйлануларны яңа чынбарлыкка әверелдерә: шомлы, ямьсез, куркыныч, бозым-чир-сихерле, караңгы Карачутыр дөньясы һәм тыныч, матур Акъәни дөньясы. Ике карчыкның көнкүреше бер-берсенә каршы куела. Карачутыр йортындагы каралык − Акъәни йортындагы аклык, Карачутыр сихеренең − чиркангыч, Акъәни имләү-өшкерүләренең мавыктыргыч булуы, Акъәнинең көн белән, Карачутырның төн белән яшәве − болар барысы да сюжеттагы ак һәм караны, яхшылык белән явызлыкны алдан ук аерып куя.

Мондый әсәрләрдә язучының геройлары архетипик образ-модельләр хасил итә. Рациональ тормыш тәҗрибәсе һәм милли гореф-гадәтләр сакчысы, ата-бабалар, өлкән буын мирасын тапшыручы, халык акылын гәүдәләндергән Бөек ана (изге карчык) архетипибы Акъәни («Күке төкреге»), Сузгын («Болан»), Камәр карчык («Ут күбәләге»), Шарлотта («Китәм, димә») һ.б. образларда калка. Идеаллаштырылган үзәк героинялар табигать белән янәшәлектә сурәтләнә.

Язучының бер төркем әсәрләрендә абсурд, реаль һәм ирреаль дөньяларны аерып булмый торган пародоксаль ситуация тудырыла, кеше ышанмаслык хәлләр тасвирлана. Әйтик, «Тамга» (2004) әсәрендә Сәфринәнең кечкенә улына карата битарафлыгы соң чиккә җиткереп

сурәтләнә: анасы тарафыннан кыш көне суык ызбада ташланган 3-4 яшьлек бала эт имеп көн итәргә мәҗбүр. Әлеге чынбарлыкта булган хәлләр баланың атасы Нурихан тарафыннан саташу кебек кабул ителә.

Моңа охшаш ситуация Н. Гыйматдинованың «Елан» (1998) повестенда да чагылыш таба. Фәһимә байлык өчен газиз баласыннан баш тарта. Язучы ана-бала арасындагы мөнәсәбәтләрнең мөһимлеген, киләчәк буыннарны тәрбияләүдә ата-ананың доминант ролен, шул ук вакытта ананың түбән дәрәҗәгә төшүен ассызыклап, бүгенге көн афәтен күрсәтә, чаң суга.

Әсәрләрдә төшләнү, саташу алымы теге һәм бу дөньяны, реальлек һәм ирреальлекне тоташтыручыга әверелә. «Каракош» (1995) әсәрендә төп геройның төшләре реаль тормышта кабатлана, ә реаль күренешләр шул дәрәҗәдә фантастик, ышанмаслык, хәтта герой әлеге хәлләрне төш кенә дип исәпли, төштәге хәлләрне өн дип уйлый.

Шулай итеп, Н. Гыйматдинованың иҗат дөньясында мифологик мотивларга һәм геройларга, төш, саташу, вакыт белән уйнау кебек психологизм алымнарына өстенлек бирелә. Геройлар гадәттән тыш вакыйгалар эчендә сурәтләнә, бер үк вакытта язучы иялләнгән һәм сәер хәлләрнең, гаҗәеп вакыйгаларның, төрле вакыт (бигрәк тә үткән һәм бүгенге), яшәү рәвеше, язмышларның кушылмасын хасил итә белә. Аның иҗат тәҗрибәләре татар әдәбиятында билгеле бер үзгәрешләр китереп чыгара.

**Использованные источники:**

1. Гыйматдинова Н.М. Бер тамчы ярату: повестьлар, хикәяләр. Казан: Татар.кит.нәшр., 2006. 351б.

2. Гыйлаҗева – Хәмидуллина Р. Сихерчеләр кирәк дөньяда // Казан утлары. 1994. №4. 175 б.

3. Заһидуллина Д. Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). Казан: Мәгариф, 2006. 255 б.